# КОМПОЗИТОР, ҖЫРЧЫ, ПЕДАГОГ М.Г.ИМАШЕВНЫҢ ТОРМЫШЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ЭШЧӘНЛЕГЕ

*Әскәрова Л. Р.*

# LIFE AND WORK OF THE COMPOSER, SINGER, TEACHER M.G.IMASHEV

*Askarova L. R.*



Халкыбызның сөйләм телен, дөньяга карашын, рухи һәм матди мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, йолаларын – барысын бергә туплап, бербөтен итеп өйрәнгәндә генә аның үткәнен тирәнрәк күзалларга, ерак гасырларга барып тоташкан тарихын, аерым төбәкләрдәге үзенчәлекләрен тагын да тулырак ачыкларга була.

Татарлар, җиһаныбызның бөтен почмакларына да таралып, матур гомер итәләр. Пермь крае Барда районында бүгенге көндә 9 меңнән артык татар яши. Татарлар яши торган иң зур авыллар: Барда (3147 кеше), Сараши (1079 кеше), Озын Ялан (855 кеше), Үдик (789 кеше), Әрҗән (758 кеше)[1].

Күренекле татар композиторы, җырчы, педагог-мөгаллим, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1984), Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре (1999) Мәсгүт Габдрахман улы Имашев 1930 елның 5 июлендә Пермь өлкәсе Барда районының Каенавыл авылында дөньяга килгән. 3 яшь тулганда ятим калып, башта туганы Таһир абыйсында, аннары әби-бабасы йортында тәрбияләнгән[2]. Мәсгүткә бары 15 яшь тулуга – 1945–1946 елларда Иске Чат авылында, 1946–1947 елларда туган авылында авыл Советы сәркатибе, соңрак клуб һәм уку йорты мөдире булырга туры килә. Аннан соң язмыш аны Пермь шәһәренә китерә. 1949 елда ул ФЗӨ мәктәбен тәмамлый, шуннан соң аны Мотовилиха хәрби заводына тимерче-штамповщик итеп эшкә алалар. Пермь хәрби-механика техникумын 1957 елда тәмамлап, Сталин исемендәге Пермь авиация заводында мастер булып эшләп ала. Анда эшләгән елларында клубтагы драмтүгәрәккә йөри башлый, иптәшләре белән спектакльләр куялар. Көй язу сәләте дә шул елларда ачыла, әкренләп

күңел дәфтәре туплана башлый. «Кыр казлары», «Көймәдә», «Чакыру» – ул елларда язылган җырлары. 1953–1958 елларда татар-башкорт җыр һәм бию ансамблен дә җитәкли[3].

1950 еллар ахырында Казаннан килгән бер төркем артистлар, Имашевның талантын күреп, көчле, матур тавышына сокланып, аңа Казанга укырга килергә тәкъдим итәләр. 1958 елда ул Казан консерваториясенең хәзерлек бүлегенә укырга керә һәм аны 1963 елда җырчы белгечлеге буенча тәмамлый. Казан консерваториясендә Георгий Тартаковта, Владимир Вороновта вокал дәресләре ала. Бер үк вакытта Альберт Леман һәм Нәҗип Җиһанов дәресләренә дә йөрергә тырыша. Шулай итеп башкалада аның зур иҗади тормышы башлана.

Мәсгут Имашев – 1959–1964 елларда Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты, аннары театр, эстрада сәнгате өчен белгечләр әзерләүче, театр композиторы булып та эшләп ала. 1964 елда аны, Әлмәт музыка училищесын оештырырга дип, нефтьчеләр каласына директор итеп җибәрәләр. Аның тарафыннан төпле музыкаль база оештырыла, беренче педагогик коллектив туплана, студентлар сайлап алына. Әлмәт шәһәрендә беренче смотр конкурсларын да башлап оештыручы ул була. Бүгенге көндә дә Имашевның бу эше «Рухият» фонды тарафыннан дәвам иттерелә[4].

Мәсгүт Имашев 1970 елда Казанга күченә, каланың берничә музыка мәктәбендә укыта башлый. 1970–1976 елларда – Казанның П. И. Чайковский исемендәге музыка мәктәбе, 1976–1981 елларда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры директоры вазифасын башкара. 1981 елдан Казан театр училищесында эшли башлый, 16 ел дәвамында директор булып эшләве (1981–1997 еллар) әлеге уку йорты тарихының иң якты сәхифәләреннән берсе булып тора. 35 ел гомерен ул шушы училищега багышлый. Хезмәттәшләре аның кешеләргә карата гаҗәеп игътибарлы һәм ихтирамлы булуын, аның белән аралашканда югары зыялылык атмосферасы хөкем сөрүен билгеләп үтәләр. Студентлар, аеруча татар төркеме, аның вокал дәресләренә бик теләп йөриләр, күп кенә шәһәр һәм төбәк конкурсларында катнашалар, призерлар һәм лауреатлар булалар[5].

Җырчы 1958 елдан филармониядә лирик баритон тавышы белән солист буларак концертларда чыгышлар ясый башлый, гастрольләр белән Мәскәү, Ленинград, Алма-Ата, Ташкент, Свердловск, Уфа кебек зур шәһәрләрне, Татарстанның бөтен районнарын йөреп чыга. Радио һәм телевидениядә Имашевның 50 дән артык язмасы саклана.

1961 елдан Мәсгүт республика театрлары өчен көйләр яза башлый. Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры өчен Х. Вахитнең «Кайда соң син?» (1961), К. Тинчурин театрына А. Гыйләҗевнең «Ефәк баулы былбыл кош» (1973), К. Тинчуринның «Назлы кияү» (1995), Минзәлә театры өчен М. Маликованың «Моңнар төште башыма» (1992), Әлмәт татар дәүләт театрына Г. Ахуновның «Утлар яна учакта», А. Успенскийның «Ике ут арасында» әсәрләре буенча спектакльләргә көйләр иҗат итә (барлыгы 50 дән артык көй авторы).

2008 елдан М. Имашев Казан музыка көллиятендә эшли, башта фольклор вокалы сыйныфын алып бара, 2010 елдан халык хоры һәм соло җырлау бүлеге мөдире итеп билгеләнә. Аның укучылары арасында Татарстан Республикасының атказанган артистлары Илнур Нуриев, Резеда Төхвәтуллина, Извил Салихов, Фәридә Сафина, Галина Казанцева, Татарстан Республикасының халык артисты Хәния Фәрхи һ. б. бар[6].

Мәсгут Имашев халык арасында композитор һәм җырчы буларак танылды, аның җырлары милләтебезнең рухи байлыгына әверелде. Авторның «Татарстан – Ватаным минем» (И. Сирматов сүз.), «Билгесез солдат» (М. Әгъләмов сүз.), «Төзүчеләр җыры» (Г. Әхмәтҗанов сүз.), «Саубуллашу вальсы» (С. Сөләйманова сүз.), «Кыр казлары артыннан» (И. Юзеев сүз.), «Туй күлмәге» (М. Шиһапов сүз.), «Туган ягым каеннары» (И. Юзеев сүз.), «Кукмара» (Г. Зәйнәшева сүз.) кебек музыкаль әсәрләре татар җыр сәнгатенең алтын фондына кертелә.

Аларның гаиләләре дә бик музыкаль. Тормыш иптәше Фатыйма ханым гаять матур җырлый, кызлары – профессиональ биюче, оныгы исә халыкара конкурслар лауреаты, Казан консерваториясе укытучысы – Айрат Имашев[7].

100 гә якын җыр авторы, РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре һәм ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе Мәсгүт ага Имашев әле дә иҗади ниятләр белән яши һәм эш дәрте белән яна.

**Сведения об авторе:** Аскарова Лилия Раисовна, научный сотрудник Центра регионоведения и социокультурных исследований Института Татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук РТ, e-mail: askaroval@mail.ru.

**Аннотация.** Статья посвящена биографии композитора, певца и педагога М. Г. Имашева.

**Ключевые слова:** М. Г. Имашев, биография, педагог, композитор.

**Abstract.** The article is devoted to the biography of the composer, singer and teacher M. G. Imashev.

**Key words:** M. G. Imashev, biography, teacher, composer.

ИСТОЧНИКИ И ЛИТЕРАТУРА

1 Бардымский район // Tatarica. [Электронный ресурс].– Режим доступа: https://tatarica.org/ru/razdely/rossijskaya-federaciya/permskij-kraj/bardymskij-rajon (дата обращения: 16.09.2022 г.).

2 Бәдретдинова Ф. Каенавыл малае // Идел.– 2010.– № 8.

3 Әхмәтҗанова Ф. Имаш имтихан тотты // Ватаным Татарстан.– 2015.– 25 ноябрь.

4 Имашев М.Г // Альметьевская энциклопедия. [Электронный ресурс].– Режим доступа: https://almet-history.tatneft.ru/personalii/z-l/i/idr-ima/imashev-masgut-gabdrahmanovich?lang=ru (дата обращения: 19.09.2022 г.).

5 Баттал Ф. Киң диңгезнең зур корабы // Татарстан.– 2000.– № 11.

6 Галиуллина М. Кызлар күлмәгеннән башланган иҗат юлы // Сәхнә.– 2012.– № 12.

7 У обкома в Казани было серьезное внимание к нам. Чуть погрешность – сразу на ковер. [Электронный ресурс].– Режим доступа: https://www.business-gazeta.ru/article/455042 (дата обращения: 19.09.2022 г.).